| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| **СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ** |

***Решение*** ***Карар***

**2024 елның 17 декабре** **Чистай шәһәре** **№ 36/4**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Советының 2020 елның 28 октябрендәге
2/3 номерлы карарының гамәлдә булуын
туктатып тору турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96_6 һәм 220_1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2020 елның 28 октябрендәге 2/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары исәбеннән инвестиция проектлары буенча муниципаль гарантияләр бирү тәртибенең гамәлдә булуын 2025 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2020 елның 28 октябрендәге 2/3 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары исәбеннән инвестиция проектлары буенча муниципаль гарантияләр бирү тәртибенең 1.3 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2024 елның 07 августындагы 33/1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советының бюджет һәм фаразлау буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы Д.А. Иванов